# КАРАР

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге составына керүче торак Киселевка пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**21.11.2024** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 21 нче ноябрендә булып узган гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде: «Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар, һәм ялгыз өлкәннәрдән кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлегенең авылында теркәлгән, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш балигъ булган һәр гражданга 2025 елда үзара салымны 600 (алты йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотуга ризамы сез:

- традицион Күмү урыннарын төзекләндерү коймаларын ремонтлау (ККК җыю өчен контейнер мәйданчыгын төзекләндерү), зират территориясендә эскәмия ясау һәм урнаштыру); - урамнарны яктырту җайланмасы (Киселевка авылында 2х урам яктырткычы урнаштыру).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 15 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 10 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 9 җыенда катнашучы тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен 1 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлегенең Александр Бистәсе торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныргa, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.

2. «Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар, һәм ялгыз өлкәннәрдән кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлегенең Александр Бистәсе авылында теркәлгән, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш балигъ булган һәр гражданга 2025 елда үзара

салымны 600 (алты йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге жирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотуга ризамы сез:

- традицион Күмү урыннарын төзекләндерү коймаларын ремонтлау (ККК жыю өчен контейнер мәйданчыгын төзекләндерү), зират территориясендә эскәмия ясау һәм урнаштыру);

- урамнарны яктырту җайланмасы (Киселевка авылында 2х урам яктырткычы урнаштыру).

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Александр Бистәсе**
**авыл җирлеге башлыгы** **Кузнецов С.А.**